# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## 1999 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында

1 статья. 1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын керемнәр буенча - 13197103 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 13833290 мең сум күләмендә расларга.

1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 636187 мең сум күләмендә билгеләргә.

2 статья. 1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджеты керемнәре өстәлгән бәяләргә салымның бер өлеше, акцизлар, предприятиеләр һәм оешмалар табышына салымның бер өлеше, физик затлардан керем салымының бер өлеше, сатудан салымның бер өлеше, башка салым түләүләре һәм җыемнар, максатчыл бюджет фондлары акчалары исәбеннән барлыкка килә, дип билгеләргә.

3 статья. 1999 елга жир өчен салымны һәм су хуҗалыгы системаларыннан промышленность предприятиеләре тарафыннан алына торган су өчен түләүләрне исәплəгәндә 1998 елда гамәлдә булган ставкаларны саклап калырга.

Түбәндәгеләр жир өчен салым түләүдән азат ителәләр:

- мобилизацияләү максатында объектлар урнаштырылган, консервацияләнгән һәм агымдагы җитештерүдә файдаланылмаган мобилизация куәтләре, сынау полигоннары һәм мобилизацияләү резервына һәм мобилизацияләү запасларына салынган матди хәзинәләрне саклау складлары урнаштырылган җирләрдән файдаланган өчен предприятиеләр һәм оешмалар;

- аэродромнар, аэропортлар, ремонт базасы, портлар урнашкан җирләр, шул исәптән су белән капланган җирләр өчен елга, һава һәм автомобиль транспорты предприятиеләре һәм оешмалары.

Тимер юл транспорты предприятиеләре тимер юллар тирәсе полосасындагы җирләр өчен авыл хуҗалыгында файдаланылучы җирләргә билгеләнгән җир салымы ставкасының 25 проценты күләмендә салым түлиләр.

4 статья. 1999 елга алкоголь продукциясен сатудан салым ставкаларын - 5 процент күләмендә, билгеләнгән исемлек нигезендә азат ителә торганнардан гайре, акчага ваклап һәм күпләп сатылган башка товарлар, башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр хакыннан 3 процент күләмендә билгеләргә.

Сатудан салымның 40 проценты - Татарстан Республикасының республика бюджетына, 60 проценты шәһәрләр һәм районнар бюджетларына күчерелә.

Салым ставкалары, сатудан салымны түләү тәртибе һәм вакытлары, шулай ук сатудан салымнан азат ителә торган товарларның (эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең) өстәмә исемлеге "Татарстан Республикасында сатудан салым турында" Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.

5 статья. 1999 елга чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләү ставкаларын чыгарылган табигый байлыкны сату бәясенә карата түбәндәге процентларда билгеләргә (моңа өстәлгән бәяләргә салым һәм акцизлар керми):

| т/с | Файдалы казылмаларның (чималның) төрләре | Ставка |
|---|---|---|
| 1. | Нефть һәм газ | 6 |
| 2. | Табигый битум | 4 |
| 3. | Гипс ташы | 4 |
| 4. | Фосфоритлар | 4 |
| 5. | Цемент чималы | 4 |
| 6. | Туфракны известьләү өчен карбонат токымнары | 3 |
| 7. | Карбонат токымнары | 3 |
| 8. | Киселгән таш | 3 |
| 9. | Бут һәм вак таш өчен төзелеш ташы | 3 |
| 10. | Ком-гравий катнашмасы | 4 |
| 11. | Пыяла һәм формалау комы | 4 |
| 12. | Төзелеш комы | 3 |
| 13. | Бентонит балчыклары | 4 |
| 14. | Керамзит балчыклары | 4 |
| 15. | Кирпеч балчыклары | 2,5 |
| 16. | Глауконитлар, цеолитлар | 4 |
| 17. | Торф, торфовивианит | 3 |
| 18. | Җир асты сулары | 6 |

1999 елда җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен түләүләр бюджет дәрәҗәләре буенча түбәндәгечә бүленә, дип билгеләргә (процентларда):

| Түләүләрнең төрләре | Бюджетлар буенча бүленеш | |
| --- | --- | --- |
| | республика | районнар (шәһәрләр) |
| 1. Файдалы казылмаларны чыгарган өчен түләүләр | | |
| - торф, сапропель, җир асты сулары һәм минераль сулар буенча; | - | 100 |
| - гомум таралган файдалы казылмалар буенча; | - | 100 |
| - нефть, газ, Идел һәм Кама елгалары үзәннәреннән чыгарылучы ком-вак таш катнашмасы, табигый битум, гипс ташы, цемент чималы буенча; | 70 | 30 |
| - файдалы казылмаларның калган төрләре буенча (фосфоритлар, бентонит балчыклары, керамзит балчыклары, төзелеш известе өчен карбонат токымнары, киселгән таш, пыяла, формалау комы, глауконитлар, цеолитлар) | - | 100 |
| 2. Файдалы казылмаларны лицензиядә билгеләнгән лимитлардан (квоталардан) артыграк кулланган өчен түләүләр 5 мәртәбәгә арттырылган ставка буенча алына; | 60 | 30 |
| - нормативлардан тыш кулланылыш билгеләгән орган счетына - 10 процент | | |
| 3. Җир куеныннан файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган максатларда файдаланган өчен түләүләр | 50 | 50 |

6 статья. Реинвестицияләүгә җибәрүне исәпкә алып, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштырудан килгән акчалар, төрле дәрәҗәдәге бюджетлар һәм хосусыйлаштыру фондлары арасында түбәндәге нормативлар буенча бүленә:

а) фондлар һәм бюджет арасында:

(процентларда)

| | Хосусыйлаштыру фондларына | Татарстан Республикасы бюджетына |
| --- | --- | --- |
| Хосусыйлаштырудан алынган акчаларның гомуми суммасы | 10 | 90 |

б) төрле дәрәҗәдәге бюджетлар арасында:

(процентларда)

| Объектларны хосусыйлаштырудан | Татарстан Республикасының республика бюджетына | Җирле бюджетларга |
|---|---|---|
| Республика милкендәге | 100 | |
| Коммуналь милектәге | | 100 |

7 статья. Предприятиеләрнең һәм оешмаларның табышына (керемenә) Татарстан Республикасы бюджетына кертелүче салым ставкасын түбәндәгечә билгеләргә:

а) предприятиеләр, оешмалар һәм чит илләрнең юридик затлары өчен - 22 процент күләмендә;

б) предприятиеләр өчен - арадашчы гамәлләреннән, алыш-биреш итүләрдән, биржалардан, брокер контораларыннан, банклардан, башка кредит һәм иминият оешмаларыннан алынган табыш буенча - 30 процент күләмендә.

8 статья. Предприятиеләрнең, оешмаларның һәм чит ил юридик затларының мөлкәткә салым ставкасын салым салынучы базаның 2 проценты күләмендә билгеләргә.

"Татнефть" АҖнең структур бүлекчәләре өлешендә предприятиеләр мөлкәтенә салымны алар урнашкан урын буенча шәһәрләр һәм районнар бюджетларына күчерергә.

1999 елда физик затларның мөлкәтенә салым ставкасын корылмаларның, биналарның һәм төзелмәләрнең инвентаризация хакыннан 0,1 процент күләмендә билгеләргә.

9 статья. "Татнефть" акционер җәмгыятенең өстәмә нефть чыгаруын кызыксындыру максатларында:

1. Зыянга эшләүче аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан 5779 мең тонна нефть чыгару өчен нефтьнең һәр тоннасына акцизларны 15 сумга кадәр киметергә, чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүнең Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелүче өлешен 50 процентка киметергә, зыянга эшләүче аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан нефть чыгаруны тәэмин итүче скважиналарны һәм төп фондларны Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелүче өлешендә мөлкәткә салымнан азат итәргә.

2. Нефть бирүчәнлекне арттыруның яңа (гидродинамик, физик-химик, җылылык, газ, геологик-физик һәм микробиологик) алымнарын куллану исәбенә 1436 мең тонна нефть чыгару өчен нефтьнең һәр тоннасына акцизларны 15 сум күләмендә билгеләргә һәм җир асты байлыклары өчен түләүдән, Татарстан Республикасының минераль

ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүләрдән азат итәргә.

3. Яңа ятмалардан 670 мең тонна нефть чыгару өчен нефтьнең һәр тоннасына акциз ставкасын 25 сумга кадәр киметү һәм җир асты байлыклары өчен түләүдән һәм Татарстан Республикасының минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларын чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүләрдән азат итәргә.

10 статья. Татарстан Республикасының нефть чыгаручы бүтән компанияләренең өстәмә нефть чыгаруларын кызыксындыру максатларында:

1. Зыянга эшләүче аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан 299 мең тонна нефть чыгару өчен нефтьнең һәр тоннасына акцизларны 15 сумга кадәр киметергә, чыгарылган файдалы казылмалар өчен түләүнең Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелүче өлешен 50 процентка киметергә, зыянга эшләүче аз дебитлы һәм күп сулы скважиналардан нефть чыгаруны тәэмин итүче скважиналарны һәм төп фондларны Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелүче өлешендә мөлкәткә салымнан азат итәргә.

2. Нефть бирүчәнлекне арттыруның яңа (гидродинамик, физик-химик, җылылык, газ, геологик-физик һәм микробиологик) алымнарын куллану исәбенә 1705 мең тонна нефть чыгару өчен нефтьнең һәр тоннасына 15 сум күләмендә акциз билгеләргә, җир асты байлыклары өчен түләүдән һәм Татарстан Республикасының минераль ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүләрдән азат итәргә.

3. Һәр тонна нефть өчен акциз ставкасын 25 сумга кадәр киметү һәм җир асты байлыклары өчен түләүдән, Татарстан Республикасының минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүләрдән азат итү исәбенә яңа ятмалардан 806 мең тонна нефть чыгарырга.

4. Углеводородларның җиңел фракцияләрен тотып алу исәбенә «ТАТЕХ» ЯАҖ чыгарган 62 мең тонна нефтьнең һәр тоннасына акцизларны 15 сумга кадәр киметергә һәм аны Татарстан Республикасының минераль ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүдән азат итәргә.

5. Нефть шламнарын яңадан эшкәртү исәбенә «Татойлгаз» ЯАҖ чыгарган 20 мең тонна нефтьнең һәр тоннасына акцизларны 15 сумга кадәр киметергә һәм аны Татарстан Республикасының минераль ресурс запасларын торгызу һәм файдалы казылмаларны чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фондына түләүдән азат итәргә.

11 статья. "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсенә ("АлАЗ" ҖБ), шулай ук "Алабуга" ирекле икътисадый зонасында башка катнашучыларга "Алабуга" ирекле икътисадый зонасы

турында" 1998 елның 22 апрелендәге Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә салым ташламалары бирергә.

12 статья. "КамАЗ" ААҖ мөлкәтенә салым ставкасын салым салу базасының 0,1 проценты күләмендә билгеләргә.

Татарстан Республикасының максатчыл бюджет фондларына түләүләр (Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фондына һәм сырхауханә кассаларына түләүләрдән гайре) буенча инвестиция салым кредиты бирергә.

"КамАЗ" ААҖ өчен комплектлаучы әйберләр җитештерүче предприятиеләргә Татарстан Республикасының республика бюджетына күчерелүче өлешендә табышка салым һәм өстәлгән бәяләргә салым буенча "КамАЗ" ААҖенә поставкалар күләмендә инвестиция салым кредиты бирергә, бу чакта исәп-хисап аерым-аерым алып барылу шарт.

13 статья. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына:

предприятиеләрнең халык куллану товарларының яңаларын җитештерүне оештыру һәм гамәлдәгеләрен җитештерүне киңәйтү буенча хупланган бизнес проектларына инвестиция салымы кредитлары бүлеп бирү хокукын;

бизнес-проектларны үтәгәндә, бирелгән инвестиция кредитлары суммасын, дәүләт милке өлеше буларак, акционер җәмгыятьләрнең устав капиталына тапшыру хокукын бирергә.

14 статья. 1999 елда Татарстан Республикасының республика бюджетына түбәндәге максатчыл бюджет фондлары акчаларын тупларга (кертергә):

Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды

"Янгын куркынычсызлыгы" махсус исәпләре

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге фонды

Татарстан Республикасының Юллар фонды

Татарстан Республикасының Экология фонды

Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды

Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә - конструкторлык эшләренең (НИОКР) республика фонды

Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды

Мәҗбүри медицина иминияте

Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру бюджеттан тыш дәүләт фонды

Татарстан Республикасының спирт, ликер-аракы һәм шәраб җитештерү промышленностен үстерүнең республика фонды

Кече эшкуарлыкка финанс ярдәменең Татарстан республика фонды.

Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясен үстерү фонды

Россия Федерациясе Салым полициясе Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсен үстерү фонды

15 статья. 1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджетына төп чыганаклар буенча керемнәрнең килерен түбәндәге суммаларда исәпләргә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Салым керемнәре - барлыгы, шул исәптән: | 5571815 |
| - предприятиеләр һәм оешмалар табышына (керемнә) салым | 849159 |
| - физик затлардан керем салымы | 121973 |
| - өстәлгән бәяләргә салым | 1817610 |
| - акцизлар | 1162000 |
| - лицензия жыемнары | 130000 |
| - сатуга салым | 240000 |
| - предприятиеләр мөлкәтенә салым | 546107 |
| - табигый байлыклардан файдаланган өчен түләүләр | 309655 |
| - жир салымы һәм жир өчен аренда түләве | 132690 |
| - чит илләрнең акчаларын, чит ил валютасында белдерелгән түләү документларын сатып алган өчен салым | 7950 |
| - башка салымнар, жыемнар һәм пошлиналар | 254671 |
| Салымсыз керемнәр - барлыгы, шул исәптән: | 679275 |
| - дәүләт милкендәге мөлкәттән яки эшчәнлектән килгән керемнәр | 219275 |
| - кире кайтару шарты белән бирелгән акчаларның килере | 400000 |
| - салымсыз башка керемнәр, штрафлар, китерелгән зыянны түләттерү | 60000 |
| Максатчыл бюджет фондлары керемнәре - барлыгы, шул исәптән: | 6946013 |
| Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фонды | 222700 |
| "Янгын куркынычсызлыгы" махсус исәбе | 69000 |
| Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 80000 |
| Татарстан Республикасының Юллар фонды | 2836559 |

233

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Экология фонды | 270000 |
| Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды | 28000 |
| Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәжрибә-конструкторлык эшләренең республика (НИОКР) фонды | 535000 |
| Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 1161308 |
| Мәҗбүри медицина иминияте | 974446 |
| Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру бюджеттан тыш дәүләт фонды | 550000 |
| Татарстан Республикасының спирт, ликер-аракы һәм шәраб җитештерү промышленностен үстерүнең республика фонды | 159000 |
| Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясен үстерү фонды | 35000 |
| Россия Федерациясе Салым полициясе Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсен үстерү фонды | 25000 |

16 статья. Татарстан Республикасының эчке дәүләт бурычының иң югары күләмен 1999 елда 1700000 мең сум итеп билгеләргә.

1999 елда Татарстан Республикасынын тышкы дәүләт бурычының иң югары күләмен 6000000 мең сумга тигез, дип билгеләргә.

17 статья. "Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләрне чикләү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында" Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы шартнамәсе нигезендә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасында бюджет мөнәсәбәтләре хакында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәте арасында төзелгән килешүне исәпкә алып, 1999 елда Татарстан Республикасы территориясеннән Федераль бюджетка түләүләр кертемен түбәндәге нормативлардан чыгып гамәлгә ашырырга:

| | | |
|---|---|---|
| норматив буенча 35%лы ставка булганда табышка салым | - | 13 процент; |
| норматив буенча 20%лы өстәлгән бәяләргә салым | - | 50 процент; |
| физик затлардан керем салымы ставка буенча | - | 1 процент. |

18 статья. Татарстан Республикасы бюджеты белән федераль бюджет арасында керемнәрне бүлешү әлеге Законның 17 статьясында билгеләнгән күләмнәрдә Татарстан Республикасының казначылык органнары тарафыннан башкарылачак.

19 статья. 1999 елда районнар һәм шәһәрләр бюджетларына түбәндәге салымнарны тапшырырга:

- салым салынучы табышның 19 проценты күләмендә предприятиеләрнең һәм оешмаларның табышына (кеременә) салымны, ә түбәндәгеләргә исә:

Әлмәт районына һәм шәһәренә - 5%, Зәй районына һәм шәһәренә - 11%, Түбән Кама шәһәренә - 5%;

- Татарстан Республикасы бюджетына физик затлардан керем салымы, ә түбәндәгеләргә исә:

Әлмәт районына һәм шәһәренә - 45%, Зәй районына һәм шәһәренә - 85%, Түбән Кама шәһәренә - 93%;

- предприятиеләрнең мөлкәтенә салымны 100 процент күләмендә, ә түбәндәгеләргә исә:

Азнакай районына һәм шәһәренә - 84%, Әлмәт районына һәм шәһәренә - 12%, Баулы районына - 88%, Бөгелмә районына һәм шәһәренә - 92%, Зәй районына һәм шәһәренә - 24%, Лениногорск районына һәм шәһәренә - 98%, Нурлат районына - 67%, Сарман районына - 36%, Түбән Кама шәһәренә - 22%.

Казан шәһәре территориясендә җитештерелгән товарларга (башкарылган эшләргә, күрсәтелгән хезмәтләргә) өстәлгән бәягә салымның 15%ын Казан шәһәре территориясендә 208580 мең сум күләмендәге капитал салуларны финанслау өчен Казан шәһәре бюджетына;

Чаллы шәһәре территориясендә җитештерелгән товарларга (башкарылган эшләргә, күрсәтелгән хезмәтләргә) өстәлгән бәягә салымның 39%ын Чаллы шәһәре бюджетына тапшырырга.

20 статья. Татарстан Республикасының район һәм шәһәр халык депутатлары Советлары 1999 елга үз бюджетларын формалаштырганда, территорияләрендә җыелучы физик затлар мөлкәтенә салымның бер өлешен, физик затлардан керем салымының бер өлешен, җир өчен салымның бер өлешен җирле үзидарә органнарына, җирле үзидарә органнарын һәм башка бюджет учреждениеләрен тоту буенча тиешле сумма чыгымнарын да кертеп, тапшыруны тәкъдим итәргә.

21 статья. 1999 елга Татарстан Республикасының республика бюджетында агымдагы чыгымнарны финанслау өчен ассигнованиеләрнең гомуми күләмен - 8038418 мең сум дип, үсеш бюджетын финанслау өчен, капитал салуларны да кертеп, 5794872 мең сум, дип билгеләргә.

235

22 статья. 1999 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан ассигнованиеләрне түбәндәге максатларга юнәлтергә:

(мең сумнарда)

| | | Барысы | шул исәптән: агымдагы чыгымнар бюджеты | шул исәптән: үсеш бюджеты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Дәүләт идарәсенә, | 218617 | 218617 | |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 4386 | 4386 | |
| 2. | Суд хакимиятенә | | | |
| | - Татарстан Республикасы Югары арбитраж судына, | 5104 | 5104 | |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 29 | 29 | |
| | - Татарстан Республикасы Конституция судына (Татарстан Республикасы Конституция суды сайланганга кадәр Татарстан Республикасының Конституция күзәтчелеге комитетын финанслауга чыгымнарны сакларга), | 430 | 430 | |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 3 | 3 | |
| 3. | Халыкара эшчәнлеккә | 19496 | 19496 | |
| 4. | Хокук саклау эшчәнлегенә һәм иминлекне тәэмин итүгә, | 440513 | 399036 | 41477 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 19594 | 19594 | |
| 5. | Фәнгә, | 25000 | 21994 | 3006 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 1427 | 1427 | |
| 6. | Промышленность, энергетика һәм төзелешкә | | | |
| | - халыкка ягулык өчен дотациягә (каты ягулыкка һәм газга) | 27292 | 27292 | |
| | - торак-төзелеш кооперативларына | 7000 | 7000 | |
| 7. | Авыл хуҗалыгына | | | |
| | - авыл хуҗалыгына | 1033039 | 773039 | 260000 |
| | - Ветеринария баш идарәсенә | 43600 | 43600 | |
| | - ачы туфракларны известләүгә | 100000 | 100000 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | - азык-төлек продуктлары буенча дәүләт заказын барлыкка китерү өчен кире кайтару шарты белән товар кредиты | 400000 | 400000 | |
| 8. | Әйләнә-тирә мохитне һәм табигый байлыкларны саклауга | | | |
| | - урман хуҗалыгына | 72000 | 72000 | |
| | - әйләнә-тирә табигать мохитен саклауга | 12000 | 12000 | |
| 9. | Җир реформасы белән бәйле гамәлләр өчен чыгымнарга | 32690 | 32690 | |
| 10. | Транспорт: | | | |
| | - автомобиль транспортына | 80814 | 39814 | 41000 |
| | - су транспортына | 10987 | 10987 | |
| | - һава транспортына | 5212 | 5212 | |
| | - тимер юл транспортына | 40354 | 40354 | |
| 11. | Торак-коммуналь хуҗалыгына, | 106894 | 106894 | |
| | шул исәптән: | | | |
| | торак фондын һәм социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итүгә һәм файдалануга тапшыруга | 100000 | 100000 | |
| 12. | Гадәттән тыш вәзгыятьләрне һәм табигый бәла-казаларны кисәтүгә һәм бетерүгә | 4000 | 4000 | |
| 13. | Мәгарифкә, | 179319 | 157319 | 22000 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 6043 | 6043 | |
| 14. | Мәдәният һәм сәнгатькә: | | | |
| | - мәдәният һәм сәнгатькә, | 209634 | 134834 | 74800 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 7036 | 7036 | |
| | - "Татарстан Республикасы халыкларының телләре турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруга | 6000 | 6000 | |
| | - кинематографиягә, | 14991 | 13991 | 1000 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 117 | 117 | |
| 15. | Массакүләм мәгълүмат чараларына: | | | |
| | - телевидениегә һәм радиотапшыруларга, | 31000 | 29000 | 2000 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 589 | 589 | |
| | - көндәлек матбугатка һәм нәшриятларга, | 37045 | 34095 | 2950 |
| | шул исәптән энергетика | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | ресурслары өчен түләүгә | 419 | 419 | |
| 16. | Сәламәтлек саклауга һәм физик тәрбиягә | | | |
| | - сәламәтлек саклауга, | 546871 | 503960 | 42911 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 10589 | 10589 | |
| | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан "КМИЗ" ААҖ аша республика дәвалау учреждениеләре өчен медицина техникасы һәм медицина әйберләре сатып алуга | 10000 | 10000 | |
| | -санитария-эпидемиология күзәтчелегенә, | 64221 | 61782 | 2439 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 5470 | 5470 | |
| | - физик тәрбиягә, | 64000 | 64000 | |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 2355 | 2355 | |
| 17. | Социаль сәясәткә | | | |
| | -социаль тәэминат учреждениеләренә, | 110871 | 110326 | 545 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 2312 | 2312 | |
| | - яшьләр сәясәтенә, | 19000 | 18000 | 1000 |
| | шул исәптән энергетика ресурслары өчен түләүгә | 224 | 224 | |
| | 1999 елга "Татарстан балалары" дәүләт программасын гамәлгә ашыруга | 10000 | 10000 | |
| | - социаль яклау чараларына, | 141426 | 141426 | |
| | шул исәптән балаларның җәйге ялын оештыруга | 25000 | 25000 | |
| 18. | Башка чыгымнарга | | | |
| | - Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең резерв фондына | 50000 | 50000 | |
| | - районнарга һәм шәһәрләргә финанс ярдәме (дотация) | 1181437 | 1181437 | |
| 19. | Дәүләт бурычларын түләү өчен, | 1050000 | 1050000 | |
| | шул исәптән Россия Саклык банкының «Татарстан» банкы каршындагы бурычы өчен | 400000 | 400000 | |
| 20. | Кыйммәтле металларның һәм кыйммәтле ташларның дәүләт | | | |

238

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | фондын барлыкка китерү | 30000 | 30000 | |
| 21. | Республика инвестиция программасына | 441420 | | 441420 |
| | Болардан тыш, Татарстан Республикасында искергән торакларны бетерү программасын гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондының берләштерелмәгән бюджетындагы акчалар - 1361000 | | | |
| 22. | Кече эшкуарлыкка булышу (кире кайтару шарты белән) | 25000 | | 25000 |
| 23. | Максатчыл бюджет фондлары чыгымнарына барысы, шул исәптән: | 6946013 | 2112689 | 4833324 |
| | - Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү фонды | 222700 | 218700 | 4000 |
| | - "Янгын куркынычсызлыгы" махсус исәбе | 69000 | 40780 | 28220 |
| | - Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе Юл хәрәкәте иминлеге фонды | 80000 | 17100 | 62900 |
| | - Татарстан Республикасының Юллар фонды | 2836559 | 448858 | 2387701 |
| | - Татарстан Республикасының Экология фонды | 270000 | 86000 | 184000 |
| | - Татарстан Республикасының Хосусыйлаштыру фонды | 28000 | 28000 | - |
| | - Гомумтармак һәм тармакара фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре (НИОКР) республика фонды | 535000 | 28518 | 506482 |
| | - Татарстан Республикасының Минераль ресурслар запасларын торгызу һәм файдалы казылмалар чыгаруның нәтиҗәлелеген арттыру фонды | 1161308 | 148181 | 1013127 |
| | - Мәҗбүри медицина иминияте | 974446 | 974446 | - |
| | - Районнарны, шәһәрләрне һәм авылларны газлаштыру бюджеттан тыш дәүләт фонды | 550000 | 63102 | 486898 |

239

| | | | |
|---|---|---|---|
| - Татарстан Республикасының спирт, ликер-аракы һәм шәраб житештерү промышленностен үстерүнең республика фонды | 159000 | 28715 | 130285 |
| - Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясен үстерү фонды | 35000 | 19878 | 15122 |
| - Россия Федерациясе Салым полициясе Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсен үстерү фонды | 25000 | 10411 | 14589 |

23 статья. 1999 елга авыл хуҗалыгы өчен бюджет акчаларын бүлүне әлеге Законның 1 нче кушымтасы нигезендә 1133039 мең сум күләмендә расларга.

24 статья. 1999 елга үсеш бюджетының бюджет акчаларын бүлүне әлеге Законның 2 нче кушымтасы нигезендә 441420 мең сум күләмендә расларга.

25 статья. 1999 елга дәүләт хакимиятен гамәлгә ашыру өчен чыгымнарны 218617 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Түбәндәгеләрнең эшчәнлеген финанслау өчен чыгымнар:<br>Татарстан Республикасы Президентының, Президент Аппаратының | 14800 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының, аның Аппаратының, даими эшләүче халык депутатларының | 18361 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларының депутат вәкаләтләрен башкаруга бәйле чыгымнарын каплауга | 546 |
| Закон проектларын эшләүгә һәм аларга экспертиза үткәрүгә бәйле чыгымнарга | 1000 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советы сессияләрен үткәрүгә бәйле чыгымнарга | 2000 |
| Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитетының | 1385 |

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының | 12360 |
| Татарстан Республикасы министрлыкларының, дәүләт комитетларының, ведомстволарының һәм аларның органнарының | 147543 |
| Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең, | 1600 |
| шул исәптән: киткәннәре урынына яңа Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар уздыруга | 800 |
| Архив учреждениеләрен финанслау чыгымнары | 5022 |
| "Дәүләт хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чыгымнары | 14000 |

26 статья. Статья буенча чыгымнарны 19496 мең сум итеп расларга, шул исәптән:

Россия Федерациясе субъектларында Татарстан Республикасы вәкиллекләрен тотуга 1999 елга чыгымнарны 6553 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллегенә | 5241 |
| Татарстан Республикасының Свердлов өлкәсендәге даими вәкиллегенә | 711 |
| Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиллегенә | 601 |

Татарстан Республикасының халыкара эшчәнлеген башкару өчен 1999 елга чыгымнарны 12943 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Үзбәкстан Республикасындагы даими вәкиллегенә | 674 |
| Татарстан Республикасының Азәрбайҗан Республикасындагы даими вәкиллегенә | 534 |
| Татарстан Республикасының Казагыстан | |

| | |
|---|---|
| Республикасындагы тулы вәкаләтле вәкиллегенә | 580 |
| Татарстан Республикасының Франциядәге вәкаләтле вәкиллегенә | 3345 |
| Татарстан Республикасының Төркиядәге вәкаләтле вәкиллегенә | 2380 |
| Татарстан Республикасының Вашингтон шәһәрендәге (АКШ) даими вәкиллегенә | 3268 |
| Татарстан Республикасының Чехия һәм Словакия Республикаларындагы даими вәкиллегенә | 1210 |
| Татарстан Республикасының Кипр Республикасындагы вәкиллегенә | 952 |

27 статья. Бюджетта каралган гамәлләрне өзлексез финанслауны тәэмин итү йөзеннән, 1999 елда Татарстан Республикасының республика бюджетыннан районнар һәм шәһәрләр бюджетларына 1181437 мең сум күләмендә дотация бүлеп бирергә, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Аксубай районы | 31557 |
| Актаныш районы | 36712 |
| Алексеевск районы | 29149 |
| Алабуга районы | 66080 |
| Апас районы | 23672 |
| Арча районы | 36220 |
| Әгерҗе районы | 23625 |
| Әлки районы | 28915 |
| Әтнә районы | 21353 |
| Балтач районы | 36392 |
| Балык Бистәсе районы | 35903 |
| Биек Тау районы | 6646 |
| Буа районы | 28073 |
| Зеленодол районы | 30375 |
| Кайбыч районы | 13885 |
| Кама Тамагы районы | 18876 |
| Кукмара районы | 49752 |
| Лаеш районы | 23417 |
| Мамадыш районы | 43960 |
| Менделеев районы | 14038 |

242

| | |
|---|---|
| Минзәлә районы | 33622 |
| Мөслим районы | 23221 |
| Питрәч районы | 29677 |
| Саба районы | 21645 |
| Спас районы | 33294 |
| Тәтеш районы | 34463 |
| Теләче районы | 25367 |
| Түбән Кама районы | 59385 |
| Тукай районы | 3948 |
| Чирмешән районы | 21944 |
| Чистай районы | 27065 |
| Чүпрәле районы | 25758 |
| Югары Ослан районы | 22123 |
| Ютазы районы | 8969 |
| Яңа Чишмә районы | 10339 |
| Зеленодол шәһәре | 59997 |
| Казан шәһәре | 30000 |
| Чаллы шәһәре | 70000 |
| Чистай шәһәре | 42020 |

28 статья. Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына 1999 елга иминләштерү кертеме ставкасын, милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм башка хуҗалык итүче субъектлар өчен, хезмәт өчен түләүнең һәрьяклап исәпләнгән суммасына карата 1,5 процент күләмендә билгеләргә.

1999 елда иминләштерү кертемнәре түләүдән азат итүнең 1997 елга билгеләнгән шартларын саклап калырга.

Татарстан Республикасы Халыкны эш белән тәэмин итү фондының 1999 елга бюджетын керемнәр буенча 222700мең сум, чыгымнар буенча 222700мең сум итеп расларга.

1999 елда Халыкны эш белән тәэмин итү фонды бюджеты керемнәре түбәндәге чыганаклар исәбенә туплана:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Социаль салым | 199300 |
| Башка төрле керемнәр | 23400 |

1999 елда Халыкны эш белән тәэмин итү фонды акчалары түбәндәге максатларга юнәлдерелә:

(мең сумнарда)

| | |
|---|---|
| Эшсезлек буенча пособие түләргә, | 109071 |
| шул исәптән социаль яклау чараларына түләүләргә | 10800 |
| Эшсезләрне һәм шөгыле булмаган гражданнарны һөнәргә өйрәтүгә | 16350 |

243

| | |
|---|---|
| Вакытлыча эш белән тәэмин итүне финанслауга - барысы | 16650 |
| шул исәптән: | |
| балигъ булмаган гражданнарның эш белән тәэмин ителүен оештыру өчен вакытлыча эш урыннары булдыру | 4850 |
| - эшсез гражданнарның эш белән тәэмин ителүен оештыруга | 10900 |
| - яшьләрнең эш белән тәэмин ителүен оештыруга ("Яшьләр практикасы") | 900 |
| Вакытыннан алда пенсияләр түләүгә | 20000 |
| Эш урыннары булдыру һәм аларны саклауда эш бирүчеләргә ярдәм күрсәтүгә, барлыгы: | 1000 |
| шул исәптән: | |
| Татарстан Республикасы кече эшкуарлыгына ярдәм итүне оештыруга | 1000 |
| Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү органнарын тотуга | 32770 |
| Заем акчаларына хезмәт күрсәтү чыгымнары | 1000 |
| Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Бюджеттан тыш дәүләт торак фондына түләүләргә | 3000 |
| Башка чыгымнарга | 22859 |

29 статья. Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсенең "Янгын куркынычсызлыгы" махсус исәбенә мәҗбүри түләүләр буенча 1999 елга түбәндәге ставкаларны билгеләргә:

янгынга каршы күчмә техникалы янгыннан саклау объект бүлекчәләре булмаган барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның (бюджет оешмаларыннан гайре), Янгынга каршы дәүләт хезмәтен тоткан өчен дифференциацияләнгән түләү ставкасын төп средстволарның, тәгәлләнмәгән төзелешнең, чималның, материалларның һәм башка шундый кыйммәтләрнең, үстерүдәге һәм симертүдәге хайваннарның, аз кыйммәтле һәм тиз тузучан предметларның, тәгәлләнмәгән

244

житештерүдәге чыгымнарның, әзер продукциянең, алып сату товарларынын, башка төрле запасларның һәм чыгымнарның калдык суммасыннан 0,15 процент күләмендә;

